БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 09 2022 ел № 277

2022 елның IV кварталына Балтач муниципаль районы буенча торакның гомуми мәйданының 1 квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләрен күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында һәм «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2022 елның 14 февралендәге 61 номерлы «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыкның эксперт-консультация советы хатында язылганнарны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «2020 - 2025 елларга Балтач муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында 2022 елның IV кварталына Балтач муниципаль районы буенча торакның гомуми мәйданының 1 квадрат метрының уртача бәясен 30 299 сум 00 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов